Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы
Туембаш авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

2022 елның 11 ноябре

№3

**«Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 25 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Чуллы авылы, Хаҗи Закиров урамы, 2 А йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 25 ноябренә 17 сәгать 30 минутка Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Чуллы авылы, Хаҗи Закиров урамы, 2 А йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: « I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылардан һәм студентлардан (курсантлардан), Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Туембаш авыл җирлегенең Чуллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Чуллы авылы Хаҗи Закиров, Рәис Ваккасов урамнары буенча юлларга вак таш җәю; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру»

- Нократ Аланы-Малмыж трассасыннан Чуллы авылына кадәр килү юлын вак таш-асфальт җәеп ремонтлау; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Чуллы авылының урам юл челтәрен карап тоту, кардан чистарту, җәйге чорда территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Чуллы авылының су башнясын буяу өчен материал сатып алу, буяу һәм ремонтлау (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Чуллы авылы урамнарын яктырту өчен светодиодлы лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Чуллы авыл клубын карап тоту (пәрдәләр сатып алу)»?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Туембаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Туембаш авыл җирлеге башлыгы: И. Ф.Гарипов

ОГРН 1021607753331 ИНН 1623003900